**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2026 **Чирмешән авылы** **№ 38**

**Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен раслау хакында, 2026 елга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 06.04.2018 елгы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында» 213/пр номерлы расланган боерыгы белән, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы белән **КАРАР БИРӘМ:**

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексын 2026 елга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карарны 16,6 процент күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов